**Р.Р.Сәлахова**

**Казанский (Приволжский)Федеральный университет, Казань**

# Г.ТУКАЙ ИҖАТЫНДА ОМОМОРФЕМАЛАР

В статье рассматривается проблема омонимии татарского языка в грамматическом аспекте. На материале произведений татарского поэта Г.Тукая расскрываются значения омоморфем, определяются их типы.

This article concerns the problem of homonymy in Tatar language in the grammatical aspect. The meanings of homonymous morphems and their types are exemplified by works by Tatar poet G.Tukay.

**Ключевые слова: омоним, омоморфема.**

Телдә аваз төзелешләре бер төрле, мәгънәләре төрле булган тел берәмлекләре омонимлык мөнәсәбәтләрен тудыралар. Тел тарихында омонимлык күренешенең төп өйрәнү объекты булып, нигездә, сүзләр торган. Әмма сүзнең морфологик төзелешендә лексик яки грамматик мәгънәгә ия булган башка берәмлекләр дә бар, димәк, омонимлык мөнәсәбәтләре сүзнең теләсә кайсы мәгънәле кисәгендә дә күзәтелергә мөмкин.

Татар телендә, барлык агглютинатив телләрдәге кебек, сүзләр морфемаларга бик ачык бүленәләр. Араларында төрле мәгънәле бер үк аваз төзелешенә ия булган морфемалар да байтак. Мондый морфемаларны омоним морфемалар яки омоморфемалар дип атыйлар [4, 67]. Татар телендә әлеге төшенчәгә беренчеләрдән булып игътибар бирүче тел белгече Х.Курбатов аларны грамматик омонимнарның бер төре итеп карый. “Омоморфема – телнең морфологик төзелешендә. Аваз составы бер үк, ләкин грамматик мәгънәсе бөтенләй башка булган ясагыч яки төрләндергеч кушымчалар омоморфемалар булалар”, - дип яза галим [3: 87-88]. Әмма омоморфема төшенчәсенә төрле мәгънәгә ия булган һәм төрле функция үти торган аваздаш кушымчалар яки синтаксик конструкцияләрне (омомодель) генә түгел, ә тамыр морфемаларны да кертеп карау мөһим, чөнки морфлар кебек үк, морфема да тамыр һәм

кушымча төрләргә бүленәләр. Омонимлык күренеше морфемаларның барлык төрләре арасында да күзәтелә. Шуннан чыгып аларның түбәндәге төрләрен билгеләргә мөмкин: тамыр омоморфемалар(сүзләр омонимлыгы), кушымча омоморфемалар(кушымчалар омонимлыгы), тамыр һәм кушымча омоморфемалар(сүзләр һәм кушымчалар омонимлыгы).

Матур әдәбиятта, омоморфемалар бик үзенчәлекле стилистик чара булып торалар. Бигрәк тә, поэзия жанрында аларны күпләп очратырга мөмкин, шагыйрьләр, гадәттә, сүзләрне рифмалаштыру максатыннан омоморфемалардан бик уңышлы файдаланалар. Бу үзенчәлек бөек шагыйребез Габдулла Тукай әсәрләрендә дә күзәтелә. Шагыйребез иҗатының тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнүгә караган хезмәтләрдә омонимлык мәсьәләсе, нигездә, сүзләр омонимлыгы белән генә чикләнгән. Сөекле шагыйребезнең иҗатын тагын бер кат күзәтеп чыгу, татар телендә омоморфемаларның түбәндәге төрләрен билгеләргә мөмкинлек бирде.

1.**Тамыр морфемаларның омонимлыгы**

а) <u>лексик</u>, ягъни бер үк сүз төркеменә карый торган тамыр омоморфемалар:

*Уйласаң ул якты көнне, килә күз* ***яшь;***

*Хозур ла соң! Инсан өчен бу хәл, бу* ***яшь****!(Бәйрәм вә сабыйлык вакыты)*

<u>ә) лексик – грамматик,</u> ягъни төрле сүз төркеменә караган тамыр омоморфемалар:

*Ә шулаймы? – Акча* ***барда*** *бар да дуст шул, бар да яр,*

*Акча исе чыкмый торса,* ***бар да*** *яныңнан таяр!(Теләнче).*

*Яхшылыкка эреп китәм –* ***балавыз мин,***

*Мактап сөйлим изге эшне –* ***бал авыз*** *мин;(Бер татар шгыйренең сүзләре).*

*Яратмыйм бер дә* ***остабикәләрне,***

*Сези алдарга* ***оста бикәләрне****(Татар кызларына).*

2. **Кушымча морфемаларның омонимлыгы**

а)<u>лексик</u>, ягъни яңа лексик мәгънә ясый торган сүз ясагыч кушымча омомофемалар:

*Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр там****чы****сы;*

*Кайдан алсын шигъре  шагыйрь, булмаса ильһам***чы***сы(Мәхәббәт)*

ә) <u>грамматик</u>, ягъни сүзнең грамматик мәгънәсен үзгәртә торган төр һәм төрләндергеч кушымча омоморфемалар:

*Һәм  бер эшне әнкәемнең иснә төш***ер,**

*Дисен аңар бер фәрештәң: “Коймак пеш***ер***!”(Йокы алдыннан).*

*Җиһанда, санки, бер сатлык товар***сыз,**

*Имамнар кайда аударса – авар***сыз***(Татар кызларына).*

*Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөнья***-сы-н,**

*Без үләрбез, билгеле, тик үкенечкә калма***-сын.**

б) <u>лексик-грамматик</u>, ягъни сүз ясагыч һәм граматик (төр һәм төрләндергеч) кушымча омоморфемалар:

*Тырышма нафилә җиргә вакты гаҗзеңне икърар***га:**

*Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и кар***га***!(Мөтәшагыйрьгә).*

*Тегермән әйләнә; әйләнсә дә, тартылмыйдыр яр***ма;**

*Мәшәкатьләнмә бушка көчләнеп, юл уртасын яр***ма***.(Мөтәшагыйрьгә).*

*Тип! Дөньяда ач-ялангачларны бел***мә,**

*Иске дөнья тузанын ит күзгә сөр***мә***(Дөньяда торыйкмы? – дип киңәшләшкән дустыма).*

*Бәхил бул, дуст! Мин һәм тиздән менәм дар***га,** -

*Туйсын ашап җансыз тәнне козгын, кар***га***;(Дөньяда торыйкмы? – дип киңәшләшкән дустыма).*

*Бер тигез җирдер дисәм, бассам аягымны – бат***а;**

*Күп вакытта сискәнәм, яңлыш тотып кош дип бак***а***(Өмид).*

*Караңгыдыр, күңелсездер гомер юл***ы.**

*Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры,*

*Шиксез, аның җәрәхәте  күкрәгендә*

*Яшьрен генә янып яткан хәсрәт тул***ы** *(Сәрләүхәсез).*

*Сабит сорый җентекләп, һәр нәрсәне бөртек***лә-п,**

*Әти белән әнисе җавап бирә бик ип***ләп***(Сабитның укырга өйрәнүе).*

*Китә башлады бездән инде кош***-лар;**

*Алар бездән ерак җирләрдә кыш-**ла-р*** (Сәрләүхәсез).

3. **Тамыр һәм кушымча морфемаларның омонимлыгы**: а)тамыр һәм сүз ясагыч:

*Синең якты көнең кемнәргә тан**сык**?*

*Кирәксә, яшь җиренә кара кан **сык**!(Кемне сөяргә кирәк?).*

*Сезнең әүлядыңыз сездәй әдәп**сез**,*

*Әдәпсезлектә сабит сез, әбәд **сез**(Татар кызларына).*

*“Юк ла, и Арба, Чана! – ди, - сезгә тормыш бик уң**ай**,*

*Эшләсәгез алты ай сез, ял итәсез алты **ай**(Арба, чана, ат).*

ә) тамыр+ төр һәм төрләндергеч:

***Без** сугышта юлбарыстан көчле**без***

***Без** тынычта аттан артык эшли**без** (Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре).*

***Сез**и күрдек гасырларча көтеп без, -*

*Килер**сез** дип, һәмишә күз тотып без(Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә).*

Татар телендә омоморфемаларның саны бик күп, Г. Тукай әсәрләре нигезендә генә дә шактый күп мисаллар табуга ирештек. Биредә әдипнең берничә әсәренә генә мөрәҗәгать ителде. Тулаем Г.Тукай иҗатында аларның саны бихисап булуына ышаныч зур. Дөрес, биредә морфемаларның омонимлыгын билгеләү барышында, хәзерге көндә ясалма булмаган сүзләр рәтендә каралучы кайбер сүзләргә бәйле шикле фикерләр туды. Мәсәлән,

*Өч-дүрт Бүре утырганнар каршы утка,*

*Тыршып-тыршып пешермәктә алар бутка*

*Утыралар аяк бөкләп каршы утка,*

*Болар инде тәмләп кенә ашый бутка(Кәҗә белән сарык хикәяте)* мисалында исем ясагыч ***–ка/-кә*** кушымчасы барлыгын белсәк тә, хәзерге көндә ул мәгънәле кисәкләргә таркалмый торган сүз буларак карала, шулай итеп, юнәлеш килеш кушымчасы ***–ка*** һәм **бутка** (бәлки тамыры бутау фигыленә кайтып каладыр) сүзендәге ка иҗеген ясагыч кушымча диярлек дәлил юк.

Омоморфемаларны билгеләгәндә, телнең морфонологик үзенчәлекләрен исәпкә алу бик мөһим, чөнки морфемалар чигендә күзәтелгән төрле аваз үзгәрешләре омонимик мөнәсәбәтләр туугa сәбәп була алалар. Телдәге мондый мөнәсәбәтләрне тикшерү морфонология, морфология, синтаксис, сүзъясалышы кебек тел белеменең шактый катлаулы тармаклары белән бәйле күп кенә үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

## Файдаланылган әдәбият


1. Броун В.В. Некоторые вопросы омонимии: Автореф. дис. ... канд. филол. наук.– Тбилиси, 1958.– 22 с.
2. Виноградов В.В. О грамматической омонимии в современном русском языке // Рус. яз. в школе.– 1940.– №1.– С.1–12.
3. Курбатов Х.Р. Грамматические омонимы в татарском языке // Татар теле һәм әдәбияты.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.– С.307-311.
4. Салахова Р.Р. Омонимичные суффиксы татарского языка. Казань: Gumanitarya, 2007. -204 с.
5. Татарский язык: Проблемы и исследования / Сост.: Ф.А.Ганиев.– Казань, 2000.– 432 с.
6. Татар грамматикасы: Өч томда. – Т.1. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998. – 642 б.
7. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2002. – 511 б.